СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск №528

**"Шәхси торак төзелеше, бакчачылык, яшелчәчелек һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга түләүсез бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен билгеләү турында" 2011 елның 14 декабрендәге 139 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Җир кодексына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Шәхси торак төзелеше, бакчачылык, яшелчәчелек һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарга түләүсез бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен билгеләү турында" 2011 елның 14 декабрендәге 139 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарының (Зәй муниципаль районы Советының 2019 елның 17 июнендәге 406 номерлы карары редакциясендә) 1 пунктында "0,115 га" сүзләрен "0,08 га" сүзләренә алмаштыру юлы белән үзгәреш кертергә.
2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATASTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**